# Бергә көчлебез

**Районда махсус хәрби операциядә катнашучыларның әниләрен һәм хатыннарын "Бергә көчлебез" ("Вместе сильнее") дип аталган клуб берләштерә. Шушы клуб әгъзалары узган атнада үзәк район китапханәсендә җыелды. Очрашуны китапханәнең уку залы баш китапханәчесе Гөлшат Гомәрова оештырды һәм "Защитники Отечества" фондының социаль координаторы Лариса Шәвәлиева, районның хатын-кызлар советы рәисе Миләүшә Янгирова, "Гаилә" хезмәте психологы Айгөл Низамова чакырылды.**



Бу клуб якыннары махсус хәрби операциядә катнашкан яугирләрнең гаилә әгъзаларын берләштерү, аз гына булса да дөнья мәшәкатьләреннән арындыру, ял итү, үзләрен кызыксындырган төрле осталык сәгатьләрендә катнашуны күздә тота. Шушы очрашу да җылы атмосферада узды, сөгүзәл затлар үзләрен кызыксындырган сорауларын бирде, үзара киңәшләштеләр, уй-фикерләре белән бүлештеләр.

Айгөл Айрат кызы уен форматында психологик тренинг уздырды, ул катнашучыларга ачылып китәргә ярдәм итте.

Шулай ук чарага лаеклы ялдагы педагог Альбина Хәбирова чакырылган иде. Ул хатын-кызларны үзенең кул эшләре белән таныштырды һәм кәгазьдән кәрзиннәр ясау буенча осталык сәгате үткәрде.

**Венера АРСЛАНОВА,**
**"Бергә көчлебез" клубы җитәкчесе.**
**Фото үзәк район китапханәсеннән алынды.**